МИНИСТЕРСТВО КУЛЬТУРЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘДӘНИЯТ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

27.12.2021 г. Казань № 1160од

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең биләнми торган вазыйфасына билгеләү (саклап тотыла торган хезмәткәрләр исәбенә кертү) өчен бәйге үткәрү турында нигезләмә раслау хакында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ санлы федераль закон, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең биләнми торган вазыйфасына билгеләнүгә бәйге турында» 2005 елның 1 февралендәге 112 санлы указы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең биләнми торган вазыйфаларын биләүгә һәм дәүләт органнары өчен саклап тотыла торган хезмәткәрләр исәбенә кертүгә бәйгеләр үткәрүнең бердәм алымнарын раслау турында» 2018 елның 31 мартындагы 397 санлы карары һәм «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең биләнми торган вазыйфасына билгеләү (саклап тотыла торган хезмәткәрләр исәбенә кертү) өчен бәйге уздыру турында кушымтада бирелгән нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгында бәйге комиссиясендә өч елдан артык катнашкан бәйсез эксперт әлеге боерык үз көченә кергән көннән алып алты ай узганчы үз вәкаләтләрен саклый дип билгеләргә.

Министр И.Х.Әюпова

Татарстан Республикасы
Мәдәният министрлыгының
27. 12. 2021 № 1160од
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең биләнми торган вазыйфасына билгеләү (саклап тотыла торган хезмәткәрләр исәбенә кертү) өчен бәйге уздыру турында нигезләмә

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Нигезләмәдә Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең биләнми торган вазыйфасына билгеләү (саклап тотыла торган хезмәткәрләр исәбенә кертү) өчен бәйге уздыру буенча бәйге комиссиясенең (алга таба – бәйге комиссиясе) эшләү вакытлары һәм тәртибе, шулай ук Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгында (алга таба – Министрлык) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең биләнми торган вазыйфасына билгеләү (саклап тотыла торган хезмәткәрләр исәбенә кертү) өчен бәйге уздыруның бердәм кагыйдәләре билгеләнә.

1.2. Министрлыкта Бәйге «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ санлы федераль законның (алга таба – федераль закон) 22 статьясы һәм «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең биләнми торган вазыйфасына билгеләнүгә бәйге турында» 2005 елның 1 февралендәге 112 санлы указы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең биләнми торган вазыйфаларына билгеләнү һәм дәүләт органнары өчен саклап тотыла торган хезмәткәрләр исәбенә кертүгә бәйгеләр үткәрүнең бердәм кагыйдәләрен раслау турында» 2018 елның 31 мартындагы 397 санлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясенең дәүләт граждан хезмәтендә хезмәткәрләр белән эш итүгә мәгълүмат технологияләрен кертүнең кайбер чаралары турында» 2018 елның 5 мартындагы 227 санлы карары, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте өчен саклап тотыла торган хезмәткәрләр исәбе турында нигезләмә раслау турында» 2011 елның 14 мартындагы ПУ-127 санлы указы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва белдерүче гражданнарга тест уздыруны оештыру мәсьәләләре» 2015 елның 11 декабрендәге ПУ-1192 санлы указы нигезендә уздырыла.

Бәйге дәүләт граждан хезмәте (алга таба – граждан хезмәте) вазыйфаларын биләүгә дәгъва белдерүчеләрнең һөнәри дәрәҗәсен, аларның граждан хезмәте

вазыйфасын биләү өчен билгеләнгән квалификация таләпләренә туры килүен бәяләүдән гыйбарәт.

1.3. Министрлыкта граждан хезмәтенең биләнми торган вазыйфасына билгеләнүгә бәйге Федераль закон нигезендә бәйге нигезендә биләнергә мөмкин булган граждан хезмәтенең буш вазыйфасы булганда мәдәният министрының (аның вазыйфаларын башкаручы затның) (алга таба – министр) карары белән игълан ителә.

Биләнми торган вазыйфага билгеләү өчен бәйге хокукый һәм хезмәткәрләр эше бүлеге тарафыннан оештырыла.

1.4. Министрлыкның саклап тотыла торган хезмәткәрләр исәбенә кертүгә бәйге хокукый һәм хезмәткәрләр эше бүлеге тарафыннан, Министрлыкның граждан хезмәтенең буш вазыйфаларын биләү буенча белгечләргә мөмкин булган ихтыяҗын һәм Министрлыкта саклап тотыла торган хезмәткәрләр исәбенә ел саен бәяләү уздыру нәтиҗәләре буенча оештырыла. Министрлыкның саклап тотыла торган хезмәткәрләр исәбенә кертүгә бәйге министр карары буенча игълан ителә.

1.5. Биләнми торган вазыйфага билгеләү (саклап тотыла торган хезмәткәрләр исәбенә кертү) өчен бәйге Министрлыкның бәйге комиссиясе тарафыннан әлеге Нигезләмәдә каралган тәртиптә үткәрелә.

1.6. Министрлыкта граждан хезмәтенең биләнми торган вазыйфасына билгеләү өчен бәйге түбәндәге очракларда үткәрелми:

билгеле бер чорга биләнә торган «җитәкчеләр» һәм «ярдәмчеләр (киңәшчеләр)» билгеләнешендәге граждан хезмәте вазыйфасы вәкаләтләрен биләү өчен билгеләнгәндә;

билгеле бер чорга хезмәт контракты төзелгәндә;

Федераль законның 28 статьясының 2 өлешендә, 31 статьясының 1 өлешендә һәм $60^1$ статьясының 9 өлешендә каралган очракларда, граждан хезмәткәрен дәүләт граждан хезмәтенең башка вазыйфасына билгеләгәндә;

граждан хезмәте өчен саклап тотыла торган хезмәткәрләр исәбенә кертелгән граждан хезмәткәрен (гражданинны) граждан хезмәте вазыйфасына билгеләгән очракта.

1.7. Министрлыкта граждан хезмәтенең биләнми торган вазыйфасына билгеләү өчен бәйге түбәндәге очракларда үткәрелмәскә мөмкин:

алар буенча вазыйфаи вәкаләтләрне үтәү дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләрдән файдалануга бәйле булган, Министрлык боерыгы нигезендә расланучы вазыйфалар исемлегендә аерым граждан хезмәте вазыйфаларына билгеләгәндә;

министр карары нигезендә, граждан хезмәтенең кече вазыйфалары төркеменә карый торган граждан хезмәте вазыйфаларына билгеләгәндә.

1.8. Бәйге үткәрелә торган максатлар:

сәләтләре һәм һөнәри әзерлеге нигезендә граждан хезмәтенә тигез дәрәҗәдә үтеп керүдә Россия Федерациясе гражданнарының конституциячел хокукларын, шулай ук дәүләт граждан хезмәткәрләренең бәйге нигезендә вазыйфада үсү хокукларын тәэмин итү;

граждан хезмәтенең биләнми торган вазыйфасына билгеләү өчен аеруча туры килә торган, федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләргә туры килә торган һәм бәйгегә кертелгән катнашучыларның гомуми исәбеннән катнашучыларны сайлап алу;

граждан хезмәте вазыйфаларын биләү өчен Министрлыкның саклап тотыла торган хезмәткәрләр исәбен булдыру.

1.9. Бәйгеләрне үткәргәндә хәл ителә торган бурычлар:

барлык катнашучылар өчен дә алар тарафыннан бәйге биремнәре һәм процедуралары үтәлгәндә тигез шартларны тәэмин итү;

катнашучыларны гадел һөнәри әһәмияткә ия билгеләр нигезендә бәяләү;

бәйге эшчәнлеген гамәлгә ашыру барышында алынган гадел һәм нигезләнгән күрсәткечләрне чагыштыру юлы белән, бәйгедә катнашучы затлар арасында граждан хезмәтенең биләнми торган вазыйфаларына (саклап тотыла торган хезмәткәрләр исәбенә кертүгә) карата таләпләргә туры килә торган затларны билгеләү.

1.10. Катнашучы бәйге комиссиясе карарына Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять белдерергә хокуклы.

1.11. Граждан хезмәтенең биләнми торган вазыйфасына билгеләү (саклап тотыла торган хезмәткәрләр исәбенә кертү) өчен дәгъва белдергән, ләкин бәйгедә катнашуга кертелмәгән катнашучыларның һәм бәйгедә катнашкан затларның документлары язма гаризалары буенча бәйге узган көннән соң өч ел дәвамында аларга кайтарып бирелергә мөмкин. Әлеге чор тәмамланганчыга кадәр документлар Министрлык архивында саклана, аннан соң юкка чыгарылырга тиеш. Бәйгедә катнашу өчен электрон рәвештә тапшырылган документлар өч ел дәвамында саклана, шуннан соң бетерелергә тиеш.

1.12. Бәйгедә катнашу (бәйгене үткәрү урынына бару һәм кире кайту, торак урынны яшәү өчен алып тору, яшәү, элемтә чаралары хезмәтеннән файдалану һ.б.) белән бәйле чыгымнар катнашучылар тарафыннан үз акчалары исәбеннән түләнә.

## II. Бәйге комиссиясен төзү һәм аның эш тәртибе

2.1. Министрлыкта бәйгеләр уздыру өчен министр боерыгы нигезендә даими нигездә эшләүче бәйге комиссиясе төзелә. Бәйге комиссиясе эшенең гаделлек һәм бәйсезлек дәрәҗәсен арттыру һәм төрле билгеләнештәге граждannар хезмәте вазыйфаларының төркемнәре өчен бәйгеләрне нәтиҗәле оештыру максатында, министр карары буенча аның составы үзгәртелә. Комиссия составы министр боерыгы белән раслана.

2.2. Бәйге комиссиясе рәисе, рәис урынбасары, сәркатип һәм комиссия әгъзаларыннан тора.

2.3. Комиссия рәисе бәйге комиссиясе эшчәнлегенә җитәкчелек итә. Комиссия рәисе булмый торганда, аның хокукларын һәм вазыйфаларын бәйге комиссиясе рәисе урынбасары башкара.

Бәйге комиссиясе сәркатибе комиссия эшен (гаризалар кабул итү, эшләр формалаштыру, бәйге комиссиясе карарларын рәсмиләштерү һ.б.) тәэмин итә.

2.4. Бәйге комиссиясе составына министр һәм (яки) ул вәкаләт биргән граждан хезмәткәрләре (шул исәптән биләнми торган граждан хезмәте вазыйфасына билгеләү өчен бәйге уздырыла торган хокукый һәм хезмәткәрләр эше бүлегеннән дә (саклап тотыла торган хезмәткәрләр исәбенә кертү өчен бәйге уздырыла торган граждан хезмәте вазыйфалары төркеме буенча һөнәри хезмәт эшчәнлеге өлкәсе гамәлгә ашырыла торган бүлекчәдән)), Министрлык каршындагы иҗтимагый шура вәкилләре, шулай ук законнарда билгеләнгән тәртиптә министрның рәсми мөрәҗәгате буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм хезмәткәрләр департаменты тарафыннан чакыртыла торган, хезмәткәрләргә кагылышлы технологияләр һәм граждан хезмәте мәсьәләләре буенча бәйсез белгечләр – тиешле өлкәләрдә һәм граждан хезмәтенең һөнәри хезмәт эшчәнлеге төрләрендә белгечләр булып торган фәнни, мәгариф һәм башка оешмаларның вәкилләре керә. Бәйсез белгечнең бәйге комиссиясендә катнашу вакыты өч елдан артмаска тиеш.

Министрлык каршындагы иҗтимагый шура әгъзаларының һәм бәйсез белгечләрнең гомуми исәбендә бәйге комиссиясендәге барлык әгъзаларының исәбе кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итә.

2.5. Алар буенча вазыйфаи вәкаләтләрне үтәү дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрдән файдалануга бәйле булган граждан хезмәтенең биләнми торган вазыйфасына билгеләүгә (саклап тотыла торган хезмәткәрләр исәбенә кертүгә) бәйге уздырылган очракта, бәйге комиссиясенең составы Россия Федерациясенең дәүләт сере турында законнары нигезләмәләрен исәпкә алып төзелә.

2.6. Бәйге комиссиясенең составы, бәйге комиссиясе тарафыннан кабул ителә торган карарларга йогынты ясый алырлык мәнфәгать каршылыклары барлыкка килү ихтималлыгы булмаслык итеп төзелә.

2.7. Бәйге комиссиясе утырышы граждан хезмәтенең биләнми торган вазыйфасына билгеләүгә (саклап тотыла торган хезмәткәрләр исәбенә кертүгә) кимендә ике катнашучы булган очракта үткәрелә һәм, әгәр анда аның әгъзаларының гомуми исәбеннән кимендә өчтән ике өлеше катнашса, тулы хокуклы булып санала. Бәйге комиссиясе утырышын бары тик граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче әгъзалар катнашында гына уздыру рөхсәт ителми.

2.8. Катнашучы белән турыдан-туры аерым әңгәмә үткәрмичә генә бәйге комиссиясе тарафыннан бәйгедә җиңүчене билгеләү турында карар кабул итү рөхсәт ителми.

Бәйге комиссиясе тарафыннан утырышны аның әгъзасы яки бәйгедә катнашучы тәкъдиме белән, мондый карарның сәбәбен (нигезен) күрсәтеп, видеоконференция рәвешендә (техник мөмкинлек булган очракта) уздыру турында бәйге комиссиясе карары кабул ителергә мөмкин.

2.9. Бәйге комиссиясе карары бәйгедә катнашучы зат булмаганда кабул ителә.

2.10. Бәйге нәтиҗәләре буенча бәйге комиссиясе карары ачык тавыш бирү юлы белән утырышта катнашучы әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул

ителә. Тавышлар тигез булган очракта, утырышка рәислек итүче затның тавышы хәлиткеч булып тора.

2.11. Граждан хезмәтенең биләнми торган вазыйфасына билгеләнү буенча бәйге йомгаклары буенча комиссиянең тавыш бирү нәтиҗәләре әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасына туры китерелгән үрнәктә бәйге комиссиясе карары белән рәсмиләштерелә. Саклап тотыла торган хезмәткәрләр исәбенә кертүгә бәйге нәтиҗәләре буенча комиссиянең тавыш бирү нәтиҗәләре әлеге Нигезләмәнең 2 нче кушымтасына туры китерелгән үрнәктә бәйге комиссиясе утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә.

Әлеге карар һәм беркетмәдә бәйге комиссиясе тарафыннан бәяләү нәтиҗәләре буенча тупланган балларын һәм алар биләгән урыннарны күрсәткән исемлек була.

2.12. Бәйге комиссиясе эшен оештыру һәм аны тәэмин итүне Министрлыкның хокукый һәм хезмәткәрләре эше бүлеге гамәлгә ашыра.

## III. Бәйгедә катнашучылар

3.1. Министрлыкта граждан хезмәтенең биләнми торган вазыйфасына билгеләү (саклап тотыла торган хезмәткәрләр исәбенә кертү) буенча бәйгедә катнашучыларга карата таләпләргә туры килә торган һәм бу Нигезләмәнең 3.7 пункты күздә тоткан чорда әлеге Нигезләмәнең 3.4 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырган гражданнар бәйгедә катнашуга кертелә.

3.2. Граждан хезмәтенең биләнми торган вазыйфасына (саклап тотыла торган хезмәткәрләр исәбендәге граждан хезмәте вазыйфасына) карата квалификация таләпләренә туры килмәве, шулай ук Федераль законда билгеләнгән чикләүләренә бәйле рәвештә гражданин (граждан хезмәткәре) бәйгедә катнашуга кертелми.

3.3. Министрлыкта граждан хезмәтенең биләнми торган вазыйфасына билгеләү (саклап тотыла торган хезмәткәрләр исәбенә кертү) өчен катнашучыларга карата таләпләр дәүләт граждан хезмәте турында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә билгеләнгән.

3.4. Россия Федерациясенең бәйгедә катнашу теләген белдергән гражданины Министрлыкка түбәндәгеләрне тапшыра:

әлеге Нигезләмәнең 3 нче кушымтасына туры китерелгән үрнәктә шәхси гариза;

Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган үрнәк буенча тутырылган һәм имзаланган сораунамә, фото белән;

паспорт яки аны алмаштыра торган документ (тиешле документ бәйгегә килгәч шәхсән күрсәтелә) күчермәсе;

кирәкле һөнәри белем, квалификацияне һәм эш елларын раслый торган документлар:

хезмәт (эш) урыны буенча нотариаль яки хезмәткәрләр хезмәте тарафыннан расланган хезмәт кенәгәсе күчермәсе һәм (яисә) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар һәм (яисә) гражданинның хезмәт (эш) эшчәнлеген раслаучы башка документлар (хезмәт (эш) эшчәнлеге беренче тапкыр башкарыла торган очраклардан тыш);

белеме турында һәм квалификациясе турында документларның күчермәләре, шулай ук, ихтыяры буенча, өстәмә һөнәри белем алу нәтиҗәләре буенча квалификациясен күтәрүне яки бирелүне раслый торган документларның, фәнни дәрәҗә, фәнни исем бирелү турында документларның нотариаль яктан яки эш (хезмәт итү) урыны буенча хезмәткәрләр хезмәте тарафыннан таныкланган күчермәсе;

гражданинда граждан хезмәтенә керүгә яки аны үтүгә комачаулый торган чирләрнең булмавы турында документ (Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының 2009 елның 14 декабрендәге 984н санлы боерыгы белән расланган 001-ГС/у исәпкә алу үрнәге);

Федераль законда, башка федераль законнарда, Россия Федерациясе Президенты указларында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларында каралган бүтән документлар.

3.5. Министрлыкта граждан хезмәте вазыйфасын биләп торучы һәм бәйгедә катнашу теләген белдергән граждан хезмәткәре бары тик министр исеменә гариза тапшыра.

Башка дәүләт органында вазыйфа биләүче, бәйгедә катнашу теләген белдергән граждан хезмәткәре Министрлыкка министр исеменә шәхси гариза һәм үзе тутырган, имзалаган һәм үзе граждан хезмәтен били торган дәүләт органының хезмәткәрләр хезмәте тарафыннан таныкланган, Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган үрнәктәге сораунамәне, фотосын теркәп, тапшыра.

3.6. Гражданинның (граждан хезмәткәренең) ризалыгы белән аңа дәүләт серен яки закон белән саклана торган бүтән серне тәшкил итә торган белешмәләрдән файдалануга рөхсәт бирү процедурасы рәсмиләштерелә, әгәр гражданин (граждан хезмәткәре) тарафыннан биләү өчен дәгъва белдерелгән граждан хезмәте вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларны үтәү мондый белешмәләрдән файдалануга бәйле булса.

Гражданинның министр исеменә тапшырылган белешмәләренең дөрес булу-булмавы тикшерелергә тиеш. Электрон рәвештә тапшырылган белешмәләр Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә автоматлаштырылган рәвештә тикшерелә.

3.7. Әлеге Нигезләмәнең 3.4 һәм 3.5 пунктларында күрсәтелгән документлар аларны кабул итү турында «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең хезмәткәрләр составы белән идарә итүнең бердәм мәгълүмат системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы рәсми сайтында (алга таба – Федераль мәгълүмат системасы) игълан урнаштырылган көннән башлап 21 календарь көн эчендә Министрлыкка гражданин (граждан хезмәткәре) тарафыннан шәхсән, почта аша җибәреп яисә Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә Федераль мәгълүмат системасыннан файдаланып, электрон рәвештә җибәрелә.

Документларны игътибарга лаек сәбәпсез вакытында тапшырмау, аларны тулы булмаган күләмдә яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру гражданиннан (граждан хезмәткәреннән) аларны кабул итеп алудан баш тарту өчен нигез булып тора.

Хөрмәткә лаек сәбәп аркасында документларны үз вакытында тапшырмаган очракта, аларны тулы булмаган күләмдә яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшырганда, министр аларны кабул итү вакытын күчерергә хокуклы.

## IV. Бәйгене уздыру кагыйдәләре

4.1. Бәйгеләрне уздыруга әзерлек катнашучыларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү алымнарын (алга таба – бәяләү алымнары) сайлау һәм аларга туры килә торган бәйге биремнәрен ясау, зарурлык булган очракта, граждан хезмәтенең аларны биләү буенча бәйге игълан итү ниятләнә торган буш вазыйфаларына карата граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи кагыйдәләре нигезләмәләрен гамәлдәгеләргә туры китерүне күздә тота.

4.2. Граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи кагыйдәләре нигезләмәләрен гамәлдәгеләргә туры китерү, бәяләү алымнарын сайлау һәм аларга туры килә торган бәйге биремнәрен ясау Министрлыкның мәнфәгатьле бүлекчәсе тарафыннан хокукый һәм хезмәткәрләр эше бүлеге белән килештереп гамәлгә ашырыла. Бәйге комиссиясе әгъзалары бәяләү алымнарын куллану һәм бәйге биремнәрен ясау турында тәкъдимнәр кертергә хокуклы.

Министр карары нигезендә граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи кагыйдәләрендә граждан хезмәтенең биләнми торган вазыйфаларына карата билгеле бер белгечлеккә (әзерлек юнәлешенә) карата квалификация таләпләре куелырга мөмкин.

4.3. Катнашучыларның һөнәри дәрәҗәсен, аларның квалификация таләпләренә туры килүен бәяләү өчен бәйге эшчәнлеге барышында, әңгәмә, сораунамә, төркемле фикер алышулар уздыру, документ проектын әзерләү, реферат һәм язмача башка эшләр язу, гамәли мәсьәләләр чишү яки биләнми торган граждан хезмәте вазыйфасы (граждан хезмәтенең хезмәткәрләр резервы булдырыла торган вазыйфалары төркеме) буенча вазыйфаи бурычларны үтәүгә бәйле мәсьәләләр буенча тест уздыруны да кертеп, федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына каршы килми торган бәяләү алымнары кулланылырга мөмкин.

4.4. Бәйге ике өлештә үткәрелә.

4.5. Беренче өлештә Министрлыкның хокукый һәм хезмәткәрләр эше бүлеге түбәндәгеләрне оештыра:

бәйге уздырылуы турында мәгълүмат әзерли һәм Министрлыкның һәм Федераль мәгълүмат системасының рәсми сайтларында урнаштыра, анда түбәндәгеләр күрсәтелә: граждан хезмәтенең биләнми торган вазыйфасының (хезмәткәрләр резервындагы граждан хезмәте вазыйфасының) исеме, әлеге вазыйфаны биләү өчен квалификация таләпләре, дәүләт граждан хезмәтен узу шартлары, граждан хезмәтенең буш вазыйфаларын биләү (саклап тотыла торган хезмәткәрләр исәбенә кертү) өчен катнашучылар тарафыннан тапшырыла торган документлар һәм материаллар исемлеге нигезендә тапшырылырга тиешле документларны Министрлыкта кабул итү урыны һәм вакыты, әлеге документларны кабул итү чоры, бәйге уздыруның күздә тотылган көне, аны уздыру урыны һәм тәртибе, бәяләү алымнары турында белешмәләр, граждан хезмәткәренең вазыйфаи

бурычларын, хокукларын һәм вазыйфаи бурычларны үтәмәгән (тиешенчә үтәмәгән) өчен җаваплылыкны үз эченә алган вазыйфаи кагыйдә нигезләмәләре, граждан хезмәткәренең һөнәри хезмәт эшчәнлегенең файдалылык һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре, Федераль мәгълүмат системасында урнаштырылган беренчел квалификация тестына сылтама, башка мәгълүмат материаллары;

катнашучылар тарафыннан тапшырылган документларны тикшерү;

гражданинның (граждан хезмәткәренең) квалификация таләпләренә туры килүен тикшерә (һөнәри белем дәрәҗәсе, граждан хезмәте (башка граждан хезмәтенең) чоры яки белгечлеге буенча эшләү чоры (тәҗрибәсе), әзерлек юнәлеше, вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле булган һөнәри белемнәре һәм күнекмәләре).

4.6. Дәгъва белдерүче зат бәйгедән тыш үзенең һөнәри дәрәҗәсен мөстәкыйль бәяләү өчен, беренчел квалификация тестын узарга мөмкин, бу хакта бәйге турындагы игъланда күрсәтелә.

Беренчел тестта дәгъва белдерүчеләрнең Россия Федерациясе дәүләт телен (рус телен) белү дәрәҗәсен, Россия Федерациясе Конституциясе нигезләре, дәүләт хезмәте турында һәм коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнары турындагы белемнәрен, мәгълүмат-коммуникация технологияләре өлкәсе белемнәрен һәм күнекмәләрен бәяләү өчен биремнәр була.

Беренчел тест Федераль мәгълүмат системасы рәсми сайтында урнаштырыла, аны узу мөмкинлеге дәгъва белдерүчеләр өчен түләүсез нигездә бирелә.

Дәгъва белдерүче тарафыннан беренчел тест үтү нәтиҗәләре бәйге комиссиясе тарафыннан игътибарга алына алмый һәм бәйгедә катнашу өчен документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

4.7. Тикшерү барышында гражданинның федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары нигезендә граждан хезмәтенә керүенә каршылык тудыручы шартлар булуы ачыкланган очракта, аңа бәйгедә катнаштырудан кире кагуның сәбәпләре турында министр тарафыннан язмача рәвештә хәбәр ителә. Әгәр гражданин бәйгедә катнашу өчен документларны электрон рәвештә тапшырган булса, бәйгедә катнаштырмау сәбәпләре хакында хәбәр аңа, Федераль мәгълүмат системасыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелә.

4.8. Бәйгедә катнашуга кертелмәгән, биләнми торган вазыйфага билгеләү өчен дәгъва белдерүче зат әлеге карарга Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять бирергә хокуклы.

4.9. Министрлыкта граждан хезмәтенең биләнми торган бер вазыйфасына (хезмәткәрләр резервындагы граждан хезмәте вазыйфасына) карата куелган квалификация таләпләренә туры килә торган кимендә ике катнашучы булуы бәйгенең беренче өлешен төгәлләү шарты булып тора, бу хәл катнашучыларны алга таба сайлаа алу мөмкинлеген тәэмин итә.

Бәйгедә катнашучылар булмаса яки вазыйфага квалификация таләпләренә туры килә торган бер генә катнашучы булуы ачыкланса, бәйге узмаган дип таныла. Бу очракта бердәнбер катнашучыга карата, катнашучыларның таләп ителә торган саны булмау сәбәпле, бәйге үткәрелмәгән дип хәбәр ителә.

4.10. Бәйгенең беренче өлеше тәмамлангач министр бәйгенең икенче өлешен уздыру көне (катнашу өчен документлар кабул итү тәмамланганнан соң 30 календарь көне узганчы), вакыты һәм урыны турында карар кабул итә. Дәүләт серен һәм закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләрдән файдалануга рөхсәт рәсмиләштерелгән очракта, бәйгенең икенче өлешен уздыру чорын министр билгели.

Министрлыкның хокукый һәм хезмәткәрләр эше бүлеге, бәйгенең икенче өлеше башланырга 15 календарь көн узганчы, Министрлык һәм Федераль мәгълүмат системасы рәсми сайтларында аны уздыру көне, урыны һәм вакыты турында мәгълүмат, бәйгедә катнашуга кертелгән катнашучылар исемлеген урнаштыра һәм катнашкан затларга язмача рәвештә тиешле хәбәрләр җибәрә, шул ук вакытта бәйгедә катнашу өчен документларны электрон рәвештә тапшырган катнашучыларга, – Федераль мәгълүмат системасыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә хәбәр ителә.

4.11. Бәйгенең икенче өлешендә түбәндәгеләр гамәлгә ашырыла:

«Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте һәм муниципаль хезмәт хезмәткәрләре составының бердәм мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына (алга таба – Хезмәткәрләрнең бердәм мәгълүмат системасы) катнашучылар турында мәгълүмат кертелә;

бәйге комиссиясе тарафыннан катнашучыларның һөнәри һәм шәхси сыйфатлары бәяләнә;

Министрлыкта граждан хезмәтенең биләнми торган вазыйфасына билгеләнүгә (саклап тотыла торган хезмәткәрләр исәбенә кертүгә) бәйгедә җиңүчене билгеләү турында бәйге комиссиясе карары кабул ителә;

Хезмәткәрләрнең бердәм мәгълүмат системасында бәйге нәтиҗәләрен рәсмиләштерү;

Министрлыкның һәм Федераль мәгълүмат системасы сайтларында бәйге нәтиҗәләре бастырып чыгарыла.

4.12. Бәйге уздырганда бәйге комиссиясе катнашучыларны алар тарафыннан тапшырылган белеме, граждан яисә башка төрле дәүләт хезмәтен узуы, башка төрле хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыруы турындагы документлар нигезендә, шулай ук тест, сораунамә уздыруны, шәхси әңгәмә уздыруны, реферат яки башка төрле язмача эшләр язуны, документ проектын әзерләүне үз эченә алырга мөмкин булган бәяләү алымнарын кулланып, бәйге эшчәнлеге нәтиҗәләре нигезендә бәяли. Бәйге үткәрелә торган төркем һәм вазыйфалар билгеләнешенә карап, төрле алымнар кулланыла ала. Бу вакытта катнашучы белән тест һәм аерым әңгәмә уздыру барлык катнашучылар өчен дә мәҗбүри алымнар булып тора.

Министрлык тарафыннан бәйге комиссиясе эшчәнлеге, шулай ук катнашучылар тарафыннан бәйге процедураларын узу өчен тиешле оештыру һәм матди-техник шартлар тудырыла.

4.12.1. Сораунамә бүлендек бүлекчә җитәкчесе тарафыннан бәйге үткәрелә торган мәсьәләләр буенча яисә граждан хезмәте вазыйфалары төркеме буенча саклап тотыла торган хезмәткәрләр исәбенә кертүгә бәйге үткәрелә торган, һөнәри

хезмәт эшчәнлеге өлкәсе гамәлгә ашырыла торган бүлендек бүлекчәләр җитәкчеләре тарафыннан үткәрелә.

Сораунамәгә элегрәк гамәлгә ашырылган һөнәри эшчәнлек буенча үтәлә торган вазыйфаи бурычлар, һөнәри казанышлар, катнашучы зат катнашкан чаралар (проектлар, форумнар, семинарлар һ.б.), басма матбугатларда аның мәкаләләре, мавыгулары турында, шулай ук аның тарафыннан җиткерелергә мөмкин булган тәкъдимнәр һәм (яки) тәкъдим хатлары турында сораулар кертелә.

Сораунамәгә шулай ук катнашучының гамәл кылу ниятен бәяләүгә юнәлдерелгән өстәмә сораулар да кертелергә мөмкин.

Бәйге комиссиясе утырышына кадәр 10 календарь көн кала катнашучыларга сораунамә үрнәге җибәрелә. Тутырылган сораунамә бәйге комиссиясе утырышына кимендә биш календарь көненнән соңга калмыйча катнашучылар тарафыннан бәйге комиссиясе сәркатибенә тапшырыла.

Сораунамә сорауларына җаваплар өчен билгеләр куелмый.

Катнашучыларның сораунамәләргә җаваплары аерым әңгәмә вакытында тыңлана.

4.12.2. Реферат яки язма эш өчен (алга таба – Эш) граждан хезмәтенең бәйге уздырыла торган буш вазыйфасы (саклап тотыла торган хезмәткәрләр исәбенә кертү буенча бәйге уздырыла торган граждан хезмәте вазыйфалары төркеме) буенча вазыйфаи бурычлардан, шулай ук әлеге вазыйфаларны биләү өчен квалификация таләпләреннән чыгып төзелгән сораулар яки биремнәр кулланыла.

Бәйге комиссиясенә кимендә 10 календарь көн кала катнашучыларга Эш темасы җибәрелә, ул бәйге уздырыла торган бүлендек бүлекчә җитәкчесе яисә саклап тотыла торган хезмәткәрләр исәбенә кертү буенча бәйге уздырыла торган граждан хезмәте вазыйфалары төркеме буенча һөнәри хезмәт эшчәнлеге өлкәсе гамәлгә ашырыла торган бүлендек бүлекчәләрнең җитәкчеләре тарафыннан билгеләнә һәм бәйге комиссиясе рәисе тарафыннан килештерелә.

Эш түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

язма эш күләме – ике биттән өч биткә кадәр;

шрифты – Times New Roman, зурлыгы 14, берле интервал аша.

Эш катнашучылар тарафыннан бәйге комиссиясе сәркатибенә бәйге комиссиясе утырышын уздырырга кимендә биш календарь көне калганчы тапшырыла.

